**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

# КАРАР

29 декабрь 2022 ел № 57 Уруссу штп

2023 елга Ютазы муниципаль районының
муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның
Прогноз планын (программасын) раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законга һәм Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2008 елның 30 маендагы 115 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының муниципаль мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турында» Нигезләмәсе нигезендә, «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 94 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Кушымта нигезендә 2023 елга Ютазы муниципаль районының күчемсез муниципаль милекне хосусыйлаштыру Прогноз планын (программасын) расларга.
2. Ютазы муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына 2023 елга «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә хосусыйлаштыруның Прогноз планын (программасын) тормышка ашыруны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының законлылык, регламент һәм җирлекләр Советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А. Ә. Шәфигуллин

Татарстан Республикасы
Ютазы район
Советының
«29»декабрь2022 ел
№57
карары белән расланды

**2023 елга «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милеген хосусыйлаштыру прогноз планы (программасы)**

**I бүлек. 2023 елга муниципаль милекне хосусыйлаштыру бурычлары**

2023 елга муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон, 2008 елның 30 маенда Ютазы муниципаль районы Советының N 115 карары белән расланган "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турында» Нигезләмәсе нигезендә эшләнде.

Муниципаль мөлкәт белән идарә итү системасының базар икътисады шартларында төзелә торган өлеше буларак, 2023елда муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның төп бурычлары булып «Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары функцияләрен һәм бурычларын тәэмин итү өчен файдаланылмый торган муниципаль милек структурасын хосусыйлаштыру, шулай ук «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 159-ФЗ номерлы Федераль закон, 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге күчемсез мөлкәтне һәм арендалана торган кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон таләпләрен гамәлгә ашыру тора.

2023 елда хосусыйлаштыруның төп максатлары булып тора:

- муниципаль милекне хосусыйлаштырудан район бюджетына салым булмаган керемнәр кертүне тәэмин итү;
- бюджетның керем өлешен арттыру;
- милекне карап тотуга район бюджетыннан чыгымнарны киметү.

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге икътисадында хосусыйлаштыру процессы нәтиҗәсендә структур үзгәрешләр түбәндәге сәбәпләр аркасында көтелми:

- хосусыйлаштыру өчен тәкъдим ителгән торак булмаган бинаны хосусыйлаштыруда милекче алышынганда муниципаль берәмлектәге икътисади вазгыятькә сизелерлек йогынты ясарга сәләтле производство урнаштырылмый;

Милекне сату исәбенә район бюджетына якынча 300 мең сум алу планлаштырыла.

Хосусыйлаштыруның прогноз планы (программасы) нигезендә сатуга планлаштырылган объектның якынча бәясе базар бәяләвен үткәргәннән соң төгәлләштерелергә тиеш.

Хосусыйлаштырылырга тиешле объектның фаразланган бәясе базарның килеп туган конъюнктурасыннан чыгып исәпләнә.

2023 елда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган мөлкәт исемлеге муниципаль милек структурасын алга таба оптимальләштерүне исәпкә алып тулыландырылырга мөмкин.

## II бүлек. 2023 елда хосусыйлаштыру планлаштырылган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милке

| № т/б | объект | адресы | Хосусыйлаштыру ысулы | Фаразланган сату вакыты | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Гомуми мәйданы 76,8 кв.м. булган, 16:43:100119:1454 кадастр номерлы торак булмаган биналар | Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы, Ленин ур., 14 | ачык аукцион | 2 квартал | |
| 2 | Гомуми мәйданы 69,7 кв.м. булган, 16:43:100119:1528 кадастр номерлы торак булмаган биналар | Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы, Ленин ур., 14 | ачык аукцион | 2 квартал | |